**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 31 июлендәге 2736 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 11 ноябрендәге 3941 номерлы карары белән расланган М-14 торак микрорайоны территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектына үзгәрешләр кертү турында

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 43, 45 һәм 46 статьяларына туры китереп, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 11 ноябрендәге 3941 номерлы карары белән расланган М-14 торак микрорайоны территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектына, әлеге карарга кушымта нигезендә планлаштыру проектының аерым өлешләрен раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалану өчен материаллар) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы

хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 31 июлендәге
2736 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 11 ноябрендәге 3941 номерлы карары белән расланган М-14 торак микрорайоны территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектына кертелә торган үзгәрешләр**

Әлеге үзгәрешләр капиталь төзелеш объектларын урнаштыру планлаштырыла торган зоналар чикләренең урнашу урынын үзгәртү максатыннан кертелә.

1. Кызыл линияләр, планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләре, капиталь төзелеш объектларын урнаштыру планлаштырыла торган зоналар чикләре булган планлаштыру проекты сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләрнең кушымтасы нигезендә бирергә.

2. II «Җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, шулай ук территорияне план буенча үстерү характеристикалары, шул исәптән территориядәге төзелешнең тыгызлыгы һәм параметрлары, территорияне үстерү өчен кирәкле социаль, транспорт хезмәте күрсәтү һәм инженерлык-техник яктан тәэмин итү системаларын үстерү характеристикалары турында нигезләмә» бүлегендә:

2.1. 2.1 «Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, территорияне план буенча үстерү характеристикалары» бүлекчәсендә:

2.1.1. 2.1.6 пунктта «13 741» санын «13 267» санына алмаштырырга;

2.1.2. 2.1.9 пунктта:

2.1.2.1. беренче абзацта «305,35» санын «294,04» санына алмаштырырга;

2.1.2.2. икенче һәм өченче абзацларны түбәндәге редакциядә бирергә һәм түбәндәге эчтәлектәге абзацлар һәм таблицалар өстәргә:

«Торак фондының, торак булмаган билгеләнештәге кертеп, кушып, кертеп-кушып төзелгән, аерым торучы биналарның мәйданы кимегән очракта,

ихтыяҗ күрсәткечләре әлеге планлаштыру проектына салынган нормативлар нигезендә мәйданнарның фактагы күрсәткечләреннән чыгып кими.

Этап эчендә мәйданнарның (торак һәм торак булмаган, шул исәптән кертеп төзелгән, кертеп-кушып төзелгән торак булмаган биналар арасындагы) сан ягыннан характеристикалары, үзләштерүнең тиешле этабы өчен планлаштыру проектында билгеләнгән максималь күрсәткечтән арттырмыйча, җир кишәрлекләре/җибәрү комплекслары арасында пропорциональ рәвештә үзгәртелергә мөмкин.

Алга таба проектлаганда җир кишәрлекләре өчен торак фондының тыгызлыгы һәм җир кишәрлегендә төзелеш алып бару проценты әлеге планлаштыру проектында салынган параметрлар нигезендә исәпләнә. Шуңа бәйле рәвештә иҗтимагый-торак билгеләнешендәге зона (Ж-1А) өчен торак фондының (һәр эшләтеп җибәрү комплексы/җир кишәрлеге) максималь тыгызлыгы – 19 700 кв. м/га, иҗтимагый-торак билгеләнешендәге зона (Ж-1Б) өчен – 18 800 кв. м/га, уртача катлы (биш каттан сигез катка кадәр, шул исәптән мансардалы) торак төзелешен урнаштыру зонасы (Ж-2А) – 15 500 кв. м/га.

Төзелеш проценты, беренче катны иҗтимагый-эшлекле функция өчен файдалануның минималь проценты таблица нигезендә билгеләнә.

## Билгеләнә торган чик параметрлар

<table>
<tr><th rowspan="2">Капиталь төзелеш объектларының атамасы</th><th colspan="2">Чик параметрлар</th></tr>
<tr><th>Төзелеш проценты (торак өлеше/стилобат буенча), %</th><th>Беренче катны иҗтимагый-эшлекле функция өчен файдалану проценты, %***</th></tr>
<tr><td>ЖК 1-1</td><td>60/билгеләнмәгән</td><td>10</td></tr>
<tr><td>ЖК 1-2</td><td>60/билгеләнмәгән</td><td>10</td></tr>
<tr><td>ЖК 2-1</td><td>60/билгеләнмәгән</td><td>10</td></tr>
<tr><td>ЖК 2-2</td><td>60/билгеләнмәгән</td><td>10</td></tr>
<tr><td>ЖК 2-3</td><td>60/билгеләнмәгән</td><td>10</td></tr>
<tr><td>ЖК 2-4</td><td>60/билгеләнмәгән</td><td>10</td></tr>
<tr><td>ЖК 4-2</td><td rowspan="4">60/билгеләнмәгән</td><td rowspan="4">ЖК 4-2 – 10%,<br>ЖК 4-3 – 4-5 – 0%</td></tr>
<tr><td>ЖК 4-3</td></tr>
<tr><td>ЖК 4-4</td></tr>
<tr><td>ЖК 4-5</td></tr>
</table>

* «билгеләнмәгән*» — параметрлар Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә билгеләнә;

** Беренче кат мәйданы/фасад озынлыгы буенча билгеләнә.

Иҗтимагый-җитештерү билгеләнешендәге объектлар зоналары, административ-эшлекле, иҗтимагый һәм сәүдә-көнкүреш билгеләнешендәге объектлар өчен торак билгеләнешендәге булмаган объектларны (һәр эшләтеп җибәрү комплексы/җир кишәрлеге) төзү проценты билгеләнгән:

- җир өсте өлешен төзү – 80%;

- стилобат буенча төзү – 90%;

2.1.3. 2.1.10 пунктта:

2.1.3.1. өченче абзацка «(мансарданы кертеп, биштән сигез катка кадәр)» сүзләрен өстәргә;

2.1.3.2. түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- мәдәният-ял билгеләнешендәге объектлар зонасын урнаштыру»;

2.1.4. 2.1.11 пунктына түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә:

«2.1.11. 3 чират кысаларында капиталь төзелеш объектлары характеристикалары

| № т/б | Зонаның исеме | Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зонасы төре | Урнаштыру зонасы мәйданы, га | Рөхсәт ителгән файдалану коды | Максималь гомуми торак фонды мәйданы (мең кв.м) | Кертеп, кушып, кертеп-кушып төзелгән, аерым торучы биналарның максималь гомуми мәйданы (мең кв.м) | Максималь катлар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Ж-2А | Катлар саны уртача булган торак төзелеше (мансарданы да кертеп, биштән сигез катка кадәр) | 8,23 | 2.5, 2.7, 2.7.1, 3.1.1, 3.3, 3.6.1, 4.1, 4.4, 4.6 | 42,67 | 1,15 | 7 гә кадәр, аны да кертеп |
| 2 | | Мәдәни-ял билгеләнешендәге объектлар | 0,86 | 3.6.1, 5.1.2 | Билгеләнмәгән | Билгеләнмәгән | Билгеләнмәгән» |

2.2. 2.2 «Социаль хезмәт күрсәтү системаларын план буенча үстерү характеристикалары, төзелеш параметрлары» бүлекчәсендә:

2.2.1. 2.2.1 пунктта, «Территорияне планлаштыру проекты чикләрендә яңа төзелешкә хезмәт күрсәтүче гамәлдәге һәм проектлаштырыла торган объектлар» таблицасында:

2.2.1.1. «Аерым торучы яңа төзелеш объектлары» сүзләреннән соң «*» тамгасын өстәргә;

2.2.1.2. «Егәрлек» графында унберенче юлда «20 000» санын «14 000» санына алмаштырырга;

2.2.1.3. «Атамасы» графында уникенче юлда «(ФОК) (мунча-сәламәтләндерү комплексын үз эченә алган)» сүзләрен төшереп калдырырга; «Егәрлеге» графында «Техник бирем нигезендә» сүзләрен «4 950» санына алмаштырырга;

2.2.1.4. уникенче юлдан соң түбәндәге эчтәлекле унөченче юлны өстәргә:

| **Билгеләнеше** | **Атамасы** | **Үлчәү берәмлеге** | **Егәрлеге** | **Төзелеш мәйданы, кв.м** | **Төзелеш күләме, куб.м** | **Җирки шәрлеге** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «- | Физкультура-сәламәтләндерү комплексы (мунча-сәламәтләндерү комплексын үз эченә алган) | Гомуми мәйданның кв.м | Техник бирем нигезендә | Техник бирем нигезендә | Техник бирем нигезендә | 0,86» |

2.2.1.5. «Атамасы» графасында егерме беренче юлда «Трансформатор подстанциясе» сүзләреннән соң «**» тамгасын өстәргә;

2.2.1.6. таблицага түбәндәге эчтәлектәге искәрмәләр өстәргә:

«*Торак фондының, торак булмаган билгеләнештәге кертеп, кушып, кертеп-кушып төзелгән, аерым торучы биналарның мәйданы кимегән очракта, ихтыяҗ күрсәткечләре әлеге планлаштыру проектына салынган нормативлар нигезендә мәйданнарның факттагы күрсәткечләреннән чыгып кими.

**Якынча урнаштыру урыны проектлауның киләсе этапларында төгәлләштерелә»;

2.2.2. 2.2.2 пунктта дүртенче абзацта «ОД-2» сүзен «ФОК» сүзенә алмаштырырга;

2.2.3. 2.2.3 пунктта:

2.2.3.1. беренче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Проектлаштырыла торган торак төзелеше өчен мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урыннар белән тәэминителеш фатирларның гомуми мәйданының 10 мең кв.метрына 27 урын тәшкил итә, гомуми белем бирү мәктәпләрендә урыннар белән тәэмин ителеш фатирларның гомуми мәйданының 10 мең кв.метрына 57 урын тәшкил итә»;

2.2.3.2. икенче абзацта «1098» санын «1059» санына, «2326» санын «2245» санына алмаштырырга;

2.3. 2.3 «Транспорт хезмәте системасын үстерү характеристикалары» бүлекчсендә, 2.3.3 пунктта:

2.3.1. икенче абзацка «, Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре)» сүзләрен өстәргә;

2.3.2. өченче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Төзелешнең III чираты өчен (Ж-2А) яшәүчеләрнең автотранспортын даими саклау һәм парковкага куюу өчен автомобиль кую урыннарында таләп ителә торган тәэмин ителеш, хезмәт күрсәтүнең норматив радиусын исәпкә алып, фатирларның гомуми мәйданының 80 кв. метрына 1 машина урыны тәшкил итә»;

2.3.3. өченче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Төзелешнең III чираты өчен (Ж-2А) торактагы автомобильләр өчен электр энергиясен җыю станциясе белән өстәмә парковка урыннарын исәпләү нормативы торакның гомуми мәйданының 10 мең кв.метрына 1 машина урыны тәшкил итә.

Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 44.2 статьясындагы 3.7 пункты нигезендә гомуми мәйданы 1000 кв. метрдан артыграк булган Б-объектлар бер объектка кимендә 1 электр энергиясе җыю станциясе исәбеннән автомобильләр өчен электр энергиясен җыю станцияләре белән тәэмин ителергә тиеш»;

2.3.4. тугызынчы абзацта «700» санын «705» санына, «278» санын «245» санына алмаштырырга, «ОД-1» сүзеннән соң «һәм ОД-2» сүзләрен өстәргә;

2.3.5. унынчы абзацта «1009» санын «1033» санына алмаштырырга, «ОД-1,» сүзеннән соң «ОД-2,» сүзен өстәргә;

2.3.6. уникенче абзацта «5 730» санын «5 726» санына алмаштырырга;

2.4. 2.4 «Инженерлык-техник яктан тәэмин итү системасын үстерү характеристикалары» бүлегендә 2.4.5 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.4.5. Торак һәм иҗтимагый-көнкүреш секторының гомуми электр куллану күләме (егәрлеге) 21,9 МВт тәшкил итәчәк. 17 җир өсте трансформатор подстанциясе, өч кертеп төзелгән трансформатор подстанциясе һәм бер бүлү трансформатор подстанциясе төзү, гомуми озынлыгы 6,6 км булган кабель линияләре (10 кВ) салу каралган»;

2.5. 2.5 «Территорияне төзекләндерү һәм яшелләндерү характеристикасы» бүлегендә, 2.5.1 пунктта:

2.5.1. дүртенче абзацта «4,55» санын «4,50» санына алмаштырырга;

2.5.2. бишенче абзацта «3,17» санын «3,09» санына алмаштырырга;

3. IV «Ясала торган җир кишәрлекләре турында мәгълүматлар белән нигезләмә» бүлегендә:

3.1. икенче абзацта «31» санын «29» санына алмаштырырга;

3.2. беренче абзацтан соң түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«- 16:24:150305:5789 кадастр номерлы беренчел җир кишәрлеген бүлеп, өч җир кишәрлеге ясау»;

3.3. «Ясала торган җир кишәрлекләре исемлеге» таблицасында:

3.3.1. унөченче һәм ундүртенче юлларны төшереп калдырырга;

3.3.2. егерме өченче юлда:

3.3.2.1. «Рөхсәт ителгән файдалану төре» графасында «Капиталь төзелеш объектларын җәмәгатьчелек өчен файдалану, эшмәкәрлек, спорт» сүзләрен «Торак төзелешенә хезмәт күрсәтү, автотранспортны саклау, капиталь төзелеш объектларыннан җәмәгатьчелек өчен файдалану, коммуналь хезмәтләр күрсәтү, көнкүреш хезмәте күрсәтү, амбулатор-поликлиника хезмәте күрсәтү, мәдәни-ял итү эшчәнлеге объектлары, эшмәкәрлек, эшлекле идарә, кибетләр, банк һәм иминият эшчәнлеге, җәмәгать туклануы, кунакханә хезмәте күрсәтү, күңел ачу чаралары, автомобильләрне юу, автомобильләр ремонтлау, күргәзмә-ярминкә эшчәнлеге, транспорт чараларына ягулык салу (электромобильләр өчен электр энергиясен җыю җайланмаларын урнаштыру максатыннан), биналарда спорт белән шөгыльләнүне тәэмин итү, эчке хокук тәртибен тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;

3.3.2.2. «Рөхсәт ителгән файдалану төре коды» графасында «3.0, 4.0, 5.1» саннарын 2.7, 2.7.1, 3.0, 3.1.1, 3.3, 3.4.1, 3.6.1, 4.0, 4.1, 4.4, 4.5, 4.6, 4.7, 4.8.1, 4.9.1.3, 4.9.1.4, 4.10, 4.9.1.1, 5.1.2, 8.3» саннарына алмаштырырга»;

3.3.3. түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| **Шартлы номер** | **Рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Мәйданы, кв.м** | **Рөхсәт ителгән файдалану төре коды** | **Ызанлу проекты кысаларында каралган кадастр эшләре** |
|---|---|---|---|---|
| «:ЗУ31 | Мәдәният-ял эшчәнлеге объектлары биналарда спорт белән шөгыльләнүне тәэмин итү | 8 640 | 3.6.1, 5.1.2 | |
| **Шартлы номер** | **Рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Мәйданы, кв.м** | **Рөхсәт ителгән файдалану төре коды** | **Ызанлу проекты кысаларында каралган кадастр эшләре** |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| :ЗУ32 | Катлар саны уртача булган торак төзелеше, автомобиль транспортын саклау, көнкүреш хезмәте күрсәтү, мәдәният-ял эшчәнлеге объектлары, эшлекле идарә, кибетләр, җәмәгать туклануы, коммуналь хезмәтләр күрсәтү | 19 780 | 2.5, 2.7.1, 3.1.1, 3.3, 3.6.1, 4.1, 4.4, 4.6 | 16:24:150305:5789 кадастр номерлы беренчел җир кишәрлеген бүлеп, җир кишәрлекләре ясау» |
| :ЗУ33 | Катлар саны уртача булган торак төзелеше, автомобиль транспортын саклау, көнкүреш хезмәте күрсәтү мәдәният-ял эшчәнлеге объектлары, эшлекле идарә, кибетләр, җәмәгать туклануы, коммуналь хезмәтләр күрсәтү | 62 573 | 2.5, 2.7.1, 3.1.1, 3.3, 3.6.1, 4.1, 4.4, 4.6 | |

3.4. «Проектлау территориясендә җирле әһәмияткә ия объектларга ясала торган җир кишәрлекләре аша транспортта каршылыксыз үтүне тәэмин итү өчен планлаштырыла торган ачык сервитутлар исемлеге» таблицасында:

3.4.1. ундүртенче һәм унбишенче юлларны төшереп калдырырга;

3.4.2. түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| **Сервитутның шартлы номеры** | **Атамасы** | **Мәйданы, кв.м** | **Җир кишәрлегенең шартлы номеры** |
|---|---|---|---|
| «:С30.1 | Юл өчен сервитут | 292 | :ЗУ31 |
| :С31.1 | Юл өчен сервитут | 2 371 | :ЗУ32 |
| :С32.1 | Юл өчен сервитут | 1 265 | :ЗУ33» |

3.5. ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегендә:

3.5.1. шартлы номерлары :ЗУ 13.1, :ЗУ 13.2 булган ясала торган җир кишәрлекләре координаталарын төшереп калдырырга;

3.5.2. әлеге үзгәрешләргә 2 номерлы кушымта нигезендә :ЗУ 31, :ЗУ 32 һәм :ЗУ 33 шартлы номерлы ясала торган җир кишәрлекләре координаталарын өстәргә.


4. Ызанлау проекты сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләргә 3 номерлы кушымта нигезендәге редакциядә бирергә.

___________

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның
11 ноябрендәге 3941 номерлы карары белән расланган
М-14 торак микрорайоны территориясен планлаштыру һәм
ызанлау проектына кертелә торган үзгәрешләргә
1 номерлы кушымта

I. Фрагмент чертежа проекта планировки с указанием красных линий, границ существующих и планируемых элементов планировочной структуры, зон планируемого размещения объектов капитального строительства

Приложение №1 к изменениям, вносимым в проект планировки и межевания территории жилого микрорайона М-14, утвержденный постановлением Исполнительного комитета г.Казани от 11.11.2022 №3941



Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның
11 ноябрендәге 3941 номерлы карары белән расланган
М-14 торак микрорайоны территориясен планлаштыру һәм
ызанлау проектына кертелә торган үзгәрешләргә
3 номерлы кушымта

V. Фрагмент чертежа проекта межевания




Приложение №3 к изменениям, вносимым в проект планировки и межевания территории жилого микрорайона М-14, утвержденный постановлением Исполнительного комитета г.Казани от 11.11.2022 №3941

## Условные обозначения

**Границы территорий, линии регулирования застройки**

| | |
|---|---|
| | Граница утвержденного проекта планировки территории |
| | Граница проекта межевания |
| | Действующие красные линии улично-дорожной сети |
| | Красные линии, предлагаемые к дальнейшему установлению согласно утвержденному ППиМТ |
| | Линии регулирования застройки (минимальные отступы от границ участка) |
| | Номера существующих кадастровых участков согласно сведениям ЕГРН |
| | Границы земельных участков |
| :ЗУ1 | Номера формируемых земельных участков |
| 1 | Номера характерных точек границ формируемых земельных участков |
| | Границы планируемых публичных сервитутов для обеспечения беспрепятственного проезда через формируемые земельные участки к объектам местного значения, расположенных на территории проектирования |
| С1.1 | Номера планируемых публичных сервитутов для обеспечения беспрепятственного проезда через формируемые земельные участки к объектам местного значения, расположенных на территории проектирования |

## Перечень существующих земельных участков

| Номер кадастрового участка | Вид разрешенного использования | Площадь, м2 | Код вида разрешенного использования | Кадастровые работы в рамках ПМТ |
|---|---|---|---|---|
| 16:24:150305:5789 | Многоэтажное жилищное строительство, объекты дошкольного образования | 90 987 | 2.6<br>3.5 | Раздел исходного ЗУ |

## Перечень образуемых земельных участков

| Условный номер | Вид разрешенного использования | Площадь, м2 | Код вида разрешенного использования | Вид кадастровых работ |
|---|---|---|---|---|
| :ЗУ31 | Объекты культурно-досуговой деятельности,<br>Обеспечение занятий спортом в помещениях, | 8 640 | 3.6.1, 5.1.2 | Образование земельных участков путем раздела исходного земельного участка с кадастровым номером 16:24:150305:5789 |
| :ЗУ32 | Среднеэтажная жилая застройка,<br>Хранение автотранспорта,<br>Бытовое обслуживание,<br>Объекты культурно-досуговой деятельности,<br>Деловое управление,<br>Магазины,<br>Общественное питание,<br>Предоставление коммунальных услуг | 19 780 | 2.5, 2.7.1, 3.1.1, 3.3, 3.6.1, 4.1, 4.4, 4.6 | |
| :ЗУ33 | Среднеэтажная жилая застройка,<br>Хранение автотранспорта,<br>Бытовое обслуживание,<br>Объекты культурно-досуговой деятельности,<br>Деловое управление,<br>Магазины,<br>Общественное питание,<br>Предоставление коммунальных услуг | 62 573 | 2.5, 2.7.1, 3.1.1, 3.3, 3.6.1, 4.1, 4.4, 4.6 | |

Примечания:
1. Перечень координат характерных точек границ формируемых земельных участков в МСК-16 приведен в приложении №2 к чертежу проекта межевания.
2. Перечень планируемых сервитутов под проезды приведен в текстовой части проекта в пояснительной записке.

Цель установления планируемых публичных сервитутов - для обеспечения беспрепятственного проезда через формируемые земельные участки к объектам местного значения, расположенных на территории проектирования.